РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

02.12.2022

Буа шәһәре

№ 386/ИК-п

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районы һәм Буа шәһәре гомуми белем
бирү оешмаларында укучыларны
тукландыруны оештыру турында

Буа муниципаль районы укучыларын «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә тулы кыйммәтле һәм балансльы кайнар туклану белән тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 14 сентябрендәге 991 номерлы «Дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча һәм башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем алучыларны түләүсез кайнар туклану белән тәэмин итүгә норматив чыгымнарны раслау турында» карары, «Дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча һәм башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем алучыларны түләүсез кайнар туклану белән тәэмин итүгә норматив чыгымнарны раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022елның 14 сентябрендәге 991 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 3 октябрендәге 1065 номерлы, «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнарының гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы, «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнарының гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» карарларына таянып, Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елның 1 гыйнварыннан билгеләргә:

1.1. Төп гомуми һәм урта гомуми белем алучы шәһәр гомуми белем бирү учреждениеләре укучылары өчен көнлек туклану бәясе 64 сум 19 тиен күләмендә шул исәптән:

- уку чорында бер укучыга көненә 8 сум 80 тиен күләмендә субсидия,

- уку чорында бер укучыга көненә 55 сум 39 тиен күләмендә ата-ана кертемнәре суммасы .

1.2. Төп гомуми һәм урта гомуми белем алучы авыл гомуми белем бирү учреждениеләре укучылары өчен көнлек туклану бәясе 38 сум 80 тиен шул исәптән:

- уку чорында бер укучыга көненә 8 сум 80 тиен күләмендә субсидия,

- укыту чорында бер укучыга көненә 30 сум 00 тиен күләмендә ата- ана кертемнәре суммасы.

1.3. Башлангыч гомуми белем алучы Буа муниципаль районы укучыларын тукландыру бәясе 64 сум 19 тиен.

1.4. Төп гомуми һәм урта гомуми белем алучы шәһәр гомуми белем бирү учреждениеләре укучылары өчен ташламалы туклану бәясе 55 сум 39 тиен.

1.5. Төп гомуми һәм урта гомуми белем алучы Буа муниципаль районы авыл мәктәпләре укучылары өчен ташламалы туклану бәясе 30 сум 00 тиен.

1.6. Шәһәр гомуми белем бирү учреждениеләренең кадет сыйныфлары өчен ташламалы туклану бәясе 55 сум 39 тиен.

1.7. Буа муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларын тукландыруны оештыру тәртибе турындагы нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Буа шәһәре һәм Буа муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә 2023 елга гомуми белем бирү оешмаларының расланган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гаиләләргә адреслы һәм социаль ярдәм күрсәтү максатларында түбәндәге гаилә категорияләрен ата-ана түләвеннән азат итәргә:

- 3 һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләр;

- 5-11 нче сыйныфларда өйдә белем алучы балалар булган гаиләләр;

- сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән балалары булган гаиләләр, шул исәптән өйдә укучы гаиләләр (коры паек);

- ата-аналары 1 һәм 2 төркем инвалид булган гаиләләр (эшләмәүче гражданнар);

- сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән балалары булган гаиләләр ике тапкыр түләүсез туклану белән тәэмин ителә;

- кадет сыйныфларында белем алучы балалар булган гаиләләр («ТР Буа шәһәренең 5 нче гимназиясе» МББУ, «ТР Буа муниципаль районының Р.З. Сәгъдиев исемендәге урта гомуми белем бирү мәктәбе» МББУ);

- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Россия Федерациясе милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр һәм затлар, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны үз ирекләре белән үтәүче гражданнар, махсус хәрби операция уздыру зонасына җибәрелгән Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәте Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре арасыннан булган, ата-аналары махсус хәрби операциядә катнашкан балалы гаиләләр ;

- югарыда күрсәтелгән категориядәге гражданнарның ата-аналары махсус хәрби операциядә катнашып һәлак булганнарның (үлгән) балалы гаиләләре;

- Донецк Халык Республикасыннан, Луганск Халык Республикасыннан, Украинадан килгән балалы гаиләләр.

3. Укыту муниципаль мәгариф оешмалары тарафыннан өйдә оештырылган сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучыларны ике тапкыр бушлай ашату белән тәэмин итүне акчалата компенсация белән алыштырырга мөмкин.

4. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Финанс - бюджет палатасы» МКУ рәисенә (Әюпов Р.Р.) Буа муниципаль районы мәгариф идарәсенең бюджет язмасында күрсәтелгән максатларга тиешле финанс елына каралган акчаларны үз вакытында бүлеп бирүне тәэмин итәргә.

5. Әлеге карар имза салынган көннән законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырылырга тиеш: http//buinsk.tatarstan.ru һәм 2023 елның «01» гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Буа муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Л.Н. Садретдиновка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районы Башкарма комитеты җитәкчесе Л.Р. Шакирҗанов

Татарстан Республикасы Буа
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2022 елның 20нче
декабрендәге 386/ИК-п номерлы
карарына кушымта

Өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ Буа муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларының туклануын оештыру тәртибе турында нигезләмә.

1. Әлеге нигезләмә өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләренең 1-11 сыйныф укучылары өчен түләүсез кайнар туклану буенча социаль ярдәм чараларын бирү тәртибен билгели:

- 3 һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләрдән булган укучылар;
- 5-11 нче сыйныфларда өйдә белем алучы укучылар;
- сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән укучылар, шул исәптән өйдә белем алучы укучылар (коры паек);
- ата-аналары 1 һәм 2 төркем инвалид ( эшләмәүче гражданнар) булган укучылар);
- ике тапкыр түләүсез туклану белән тәэмин ителүче сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән укучылар;
- кадет сыйныфларында белем алучы укучылар («ТР Буа шәһәренең 5 нче гимназиясе» МББУ, «ТР Буа муниципаль районының Р.З. Сәгъдиев исемендәге урта гомуми белем бирү мәктәбе» МББУ);
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Россия Федерациясе милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр һәм затлар, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны үз ирекләре белән үтәүче гражданнар, махсус хәрби операция уздыру зонасына җибәрелгән Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәте Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре арасыннан булган, ата-аналары махсус хәрби операциядә катнашканнарның укучы балалары;
- югарыда күрсәтелгән категориядәге гражданнарның ата-аналары махсус хәрби операциядә катнашып һәлак булганнарның (үлгән) балалы гаиләләрдән булган укучылар;
- Донецк Халык Республикасыннан, Луганск Халык Республикасыннан, Украинадан килгән укучылар.

2. Укучыларны тукландыруны оештыру:

2.1. Мәгариф оешмаларында туклану буенча комиссия төзү.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларга социаль ярдәм чараларын күрсәтү комиссиясе (алга таба - комиссия) төзелә. Комиссия составы учреждение директоры тарафыннан раслана. Комиссия составына укучыларны оештыру өчен җаваплы педагогны, укучыларның ата-аналары иҗтимагый берләшмәләре вәкилләрен кертергә тәкъдим ителә. Комиссия әгъзаларының гомуми саны кимендә биш кеше булырга тиеш.

Комиссия:

- кушымта нигезендә бирелгән рәвештә укучыларның сыйныф җитәкчеләреннән социаль ярдәм чараларын бирү турында гариза кабул итә;
- 2023 елның 10 гыйнварына кадәр укучыларның исемлекләрен раслый.

2.2.Сыйныф җитәкчеләре:

- ата-аналардан яисә аларны алыштыручы затлардан әлеге Нигезләмәгә кушымта нигезендә бирелгән рәвеш буенча түләүсез туклануга гаризалар кабул итәләр
- гаризаларны алган көннән соң өч көн эчендә комиссия каравына җибәрәләр;
- категорияләр буенча сыйныфта укучыларның туклануын исәпкә алалар;
- укучылар һәм ата-аналар арасында укучыларның тулы кыйммәтле кайнар туклануы кирәклеге турында аңлату эшләре алып баралар;
- сыйныфтагы барлык укучыларының ашханәдә булуын тикшереп торалар.

2.3. Ата-аналар яисә аларны алмаштыручы затлар тапшырылган документларның дөреслеге өчен җаваплы.

2.4. Гомуми белем бирү учреждениеләре җитәкчеләре:

- бирелгән документлар нигезендә категорияләр буенча укучыларны түләүсез туклану белән тәэмин итүгә боерыклар чыгаралар;

- Буа муниципаль районы мәгариф идарәсенә категорияләр буенча укучылар исемлекләрен тапшыра;

- Мәгариф учреждениесендә балансны туклану оештырган өчен, санитария нормалары нигезендә азык-төлек блокларының торышына җаваплы.

2.5. Буа муниципаль районы мәгариф идарәсе укучыларының туклануын оештыру, азык әзерләү технологиясен үтәү, мәгариф оешмаларына чыгып, азык-төлек нокталарында санитария нормаларын үтәү мәсьәләләрен җитәкли.

Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының барлык гомуми белем бирү оешмаларына кагыла.

Өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ Буа
муниципаль районы гомуми белем
бирү учреждениеләре укучыларының
туклануын оештыру тәртибенә
кушымта

Мәктәп укучыларының туклануын оештыру комиссиясенә

______________________

______________________________________

____________________________________
( гариза бирүченең Ф.И. А,и)

______________________________________
(адрес)

______________________________________

______________________________________

Гариза

Улым (кызым, тәрбиядәге) ___________ сыйныф укучысы ___________________________________________________________________________

(Ф.И.А.и.)

___________________________________________________________________________

Түләүсез туклану белән тәэмин итүегезне сорыйм.
Гаилә әгъзасына уртача керемне __________________ сум тәшкил итә.
Өстәмә хәбәр итәм: ________________________________________________
_________________________________________________________________________
Ташламаны раслый торган документларны тапшырам

___________________________
(дата, имза)

____________________

Гаризага теркәлә:
1) Күпбалалы гаилә турында таныклык күчермәсе;
2) Балалар туу турында таныклыклары;
3) Опека һәм попечительлек бүлегеннән белешмә, яисә 3 һәм аннан да күбрәк баласы булган балигъ булмаганнарга опека билгеләү турында күрсәтмәнең күчермәсе;
4) Инвалид балалар, ивалид ата-аналар өчен Медицина – социаль экспертиза медецина белешмәсе, Психологик-медик-педагогик комиссия белешмәләре.
5) махсус хәрби операция уздыру зонасына җибәрелгән хәрби хезмәткәрләрнең ата-аналары өчен военкоматтан белешмә.